# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**дуртенче чакырышның чираттан тыш утырышы**

**29 июль 2024 ел** **№137** **Иске Җөри авылы**

**Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге 113 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 25 мартындагы 09/13-09/1319 номерлы хатын карап, Теләче районы прокурорының 2024ның 16 мартындагы Исорг-20920037-383-24/-20920037 номерлы протестын карап, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге 113 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**А**) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

торак йортлар, торак йортлар өлешләре, фатирлар, фатирлар өлешләре, бүлмәләр;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;

гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнар;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалар;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент;

5) 0,5 процент башка салым салу объектларына карата.»;

**Б**) 3 пунктның Б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Б)18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны, шулай ук белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча белем алучы

әлеге гражданнарның балаларын, укуны тәмамлаганчы, әмма 23 яшькә җиткәнче, мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

Салым льготасы күпбалалы гаиләгә туры килә торган салым салуның бер объектына карата салым түләүченең сайлавы буенча бирелә. Салым ташламасы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган объектка карата салым суммасы түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

- фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яки корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылмасы;

5) гараж яки машина-урын.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков